| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>КОРГУЗИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЮГАРЫ ОСЛАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ<br>КАРАГУЖА АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

15.12.2023 — с. Коргуза — 35

Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлегенең Патрикеево авылы гражданнарыннан үзара салым җыю тәртибе турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Уставы нигезендә Карагуҗа авыл җирлегенең Патрикеево авылы торак пунктында гражданнар җыенында кабул ителгән 2023 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы карарны гамәлгә ашыру максатларында Карагуҗа авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Патрикеево авылында гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районының
Карагуҗа авыл җирлеге башлыгы — Д.В.Плохов

Карагуҗа авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 15 декабреннән 35 номерлы карарына 1нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлегенең Патрикеево авылы гражданнарыннан үзара салым җыю тәртибе

1. Әлеге Тәртип Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлегенең Патрикеево авылында гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү 1.01.2024 елдан 25.03.2024 елга кадәр гражданнар җыенында катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлегенең Патрикеево авылы территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан башкарыла.

3. Гражданнарның түбәндәге категорияләре үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:
а) мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары.

4. Түләүләр күләме гражданнарның түбәндәге категорияләре өчен җыены турындагы карарда билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә:
а) уку йортлары студентлары,
б) күп балалы гаиләләр.

5. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы имза яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән гражданнарга җиткерелә.
Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки кечерәйтелгән күләмдә бер тапкыр түләнә торган түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Карагуҗа авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә.

7. Гражданнар түләүләрне физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисаплар башкару хокукына ия булган оешмалар (исәп-хисап оешмалары) аша яки https://uslugi.tatarstan.ru/. сылтама буенча Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша күчерү юлы белән башкара ала.

8. Түләү фактын раслау булып керем касса ордеры квитанциясе, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслый торган башка документлар тора.

9. Билгеләнгән срокта кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Карагуҗа авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 15 декабреннән 35 номерлы карарына
2нче кушымта

ХӘБӘРНАМӘ (ХӘБӘР) № ________________

Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләү турында

Түләүченең Ф.И.А.и.
______________________________________________________________________
Адрес: ______________________________________________________________
____________________________________________________________ нигезендә
сезгә _______ кадәр чараларны гамәлгә ашыру өчен ______ күләмендә
түбәндәге реквизитлар буенча:
______________________________________________________________бер тапкыр түләү
түләргә кирәк.
Алучының банкы БИК ____________________________________________
Сч. № ___________________________________________________
Алучы __ Сч. № __________________________________________
ИНН ____________________________________________
КПП ___________________________________________
КБК _______________________ОКАТО ______________________
Түләү билгеләү
________________________________________________________________________

Җитәкче _________________________________________________
М. у. (имза) (имзаны киңәйтеп язу)
- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү сызыгы - - - - - - - - - - - - - - -
Хәбәрнамә (Хәбәр) № __________________
үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләүне бюджетка түләү турында
___________________
(муниципаль берәмлек исеме)
_________________ сум күләмендә.

Түләүченең Ф.И.А.и. _____________________________
Адрес: _________________________________________________

Алдым "__" ___________________ 20____ ел _ ___________________
(түләүченең имзасы)

Искәрмә. Әгәр хәбәр түләүчегә шәхсән тапшырыла икән, киселә торган өлеше тутырыла һәм Карагуҗа авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.